# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Җир турындагы законнарны бозган өчен административ җаваплылык турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

**1 статья.** "Җир турындагы законнарны бозган өчен административ җаваплылык турында" Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1994, №1-2), түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

«Җир турындагы законнарны бозган өчен
административ җаваплылык турында

Татарстан Республикасы
ЗАКОНЫ

Әлеге Закон юридик затларның, индивидуаль эшкуарларның, урындагы затларның һәм гражданнарның Татарстан Республикасының җир турындагы законнарын бозган өчен административ җаваплылыгын билгели һәм җирләрдән рациональ файдалануны, җирләрне саклауны тәэмин итүгә юнәлдерелгән.

1 статья. Җирләрдән максатчан билгеләнешсез яисә рөхсәтсез файдалану

Җирләрдән максатчан билгеләнешсез яисә рөхсәтсез файдаланган өчен -

кисәтү ясала яисә юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга - хезмәт өчен түләүнең илледән алып йөз минималь күләменә кадәр, урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең егермедән алып утыз минималь күләменә кадәр, гражданнарга хезмәт өчен түләүнең өчтән алып ун минималь күләменә кадәр штраф салына.

**2 статья.** Җир кишәрлекләренә җир турындагы законнар нигезендә билгеләнгән йөкләүләрне бозу

Җир кишәрлекләренә җир турындагы законнар нигезендә билгеләнгән йөкләүләрне бозган өчен -

кисәтү ясала яисә юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга - хезмәт өчен түләүнең илледән алып йөз минималь күләменә кадәр, урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең өчтән алып ун минималь күләменә кадәр, гражданнарга хезмәт өчен түләүнең бердән алып өч минималь күләменә кадәр штраф салына.

**3 статья.** Вакытлыча биләнүче җирләрне кире кайтарып бирү вакытларын бозу яисә аларны максатчан билгеләнеше буенча файдаланырлык халәткә китерү вазыйфаларын үтәмәү

Вакытлыча биләнүче җирләрне кире кайтарып бирү вакытларын бозган яисә аларны максатчан билгеләнеше буенча файдаланырлык халәткә китерү вазыйфаларын үтәмәгән өчен -

юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга - хезмәт өчен түләүнен йөздән алып ике йөз минималь күләменә кадәр, гражданнарга хезмәт өчен түләүнен өчтән алып җиде минималь күләменә кадәр штраф салына.

**4 статья.** Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр туфрагының уңдырышлы катламын бозу һәм (яисә) юкка чыгару

Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр туфрагының уңдырышлы катламын бозган һәм (яисә) юкка чыгарган өчен -

юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга - хезмәт өчен түләүнең ике йөздән алып биш йөз минималь күләменә кадәр, урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең уннан алып егерме минималь күләменә кадәр, гражданнарга хезмәт өчен түләүнен дүрттән алып ун минималь күләменә кадәр штраф салына.

**5 статья.** Хуҗалык эшчәнлеген башкарганда авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир кишәрлекләреннән аларның уңдырышлылыгын түбәнәйтүгә китерүче ысуллар кулланып файдалану

Хуҗалык эшчәнлеген башкарганда авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир кишәрлекләреннән аларның уңдырышлылыгын түбәнәйтүгә китерүче ысуллар кулланып файдаланган өчен -

юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга - хезмәт өчен түләүнен илледән алып йөз минималь күләменә кадәр, урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең уннан алып егерме минималь

күләменә кадәр, гражданнарга хезмәт өчен түләүнең икедән алып биш минималь күләменә кадәр штраф салына.

6 статья. Җир кишәрлекләрен рөхсәтсез, шул исәптән алардан вакытлыча файдалану өчен дә, биләү

Җир кишәрлекләрен рөхсәтсез, шул исәптән алардан вакытлыча файдаланган өчен дә, биләгән өчен -

юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга - хезмәт өчен түләүнең йөздән алып ике йөз минималь күләменә кадәр, урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең уннан алып утыз минималь күләменә кадәр, гражданнарга хезмәт өчен түләүнең биштән алып унбиш минималь күләменә кадәр штраф салына.

7 статья. Җир кишәрлегенә хокукны таныклаучы документларны законнар нигезендә рәсмиләштермичә генә җир кишәрлегеннән файдалану

Җир кишәрлегенә хокукны таныклаучы документларны законнар нигезендә рәсмиләштермичә генә җир кишәрлегеннән файдаланган өчен -

кисәтү ясала яисә юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга - хезмәт өчен түләүнең егермедән алып утыз минималь күләменә кадәр, урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең биштән алып ун минималь күләменә кадәр, гражданнарга хезмәт өчен түләүнең икедән алып биш минималь күләменә кадәр штраф салына.

8 статья. Җир өчен түләүләрне даими рәвештә кертмәү

Җир өчен түләүләрне даими рәвештә кертмәгән өчен -

кисәтү ясала яисә юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга - хезмәт өчен түләүнең уннан алып егерме минималь күләменә кадәр, урындагы затларга хезмәт өчен түләүнең биштән алып ун минималь күләменә кадәр штраф салына.

9 статья. Авыл хуҗалыгы һәм урман хуҗалыгы житештерүенә китерелгән югалтуларны түләттерү вакытларын бозу

Авыл һәм урман хуҗалыгын алып баруга бәйле булмаган максатларда авыл хуҗалыгы җирләрен һәм урман фонды җирләрен тартып алу аркасында авыл хуҗалыгы һәм урман хуҗалыгы житештерүенә китерелгән югалтуларны түләттерүнең законнарда билгеләнгән вакытларын бозган өчен -

кисәтү ясала яисә юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга - хезмәт өчен түләүнең уннан алып егерме минималь күләменә кадәр, гражданнарга хезмәт өчен түләүнең өчтән алып ун минималь күләменә кадәр штраф салына.

10 статья. Җир турындагы законнарны бозуларны бетерү мәсьәләләре буена Татарстан Республикасының Җир ресурслары һәм жир реформасы дәүләт комитеты, аның урыннардагы органнары тарафыннан бирелгән күрсәтмәләрне үтәүдән читләшү яисә вакытында үтәмәү

Җир турындагы законнарны бозуларны бетерү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасының Җир ресурслары һәм жир реформасы дәүләт комитеты, аның урыннардагы органнары тарафыннан бирелгән күрсәтмәләрне үтәүдән читләшкән яисә вакытында үтәмәгән өчен -

юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга - хезмәт өчен түләүнең егермедән алып утыз минималь күләменә кадәр, урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең уннан алып егерме минималь күләменә кадәр, гражданнарга хезмәт өчен түләүнең биштән алып ун минималь күләменә кадәр штраф салына.

11 статья. Билгеле бер максатлар өчен бирелгән жир кишәрлекләреннән жир турындагы законнарда билгеләнгән вакытларда файдаланмау

Билгеле бер максатлар өчен бирелгән жир кишәрлекләреннән жир турындагы законнарда билгеләнгән вакытларда файдаланмаган өчен -

юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга һәм гражданнарга кисәтү ясала.

12 статья. Туфракны су һәм жил эрозиясеннән саклау, туфракның торышын начарайтырлык башка тискәре процессларны булдырмый калу буенча мәжбүри гамәлләрне үтәмәү

Туфракны су һәм жил эрозиясеннән саклау, туфракның торышын начарайтырлык башка тискәре процессларны булдырмый калу буенча мәжбүри гамәлләрне үтәмәгән өчен -

кисәтү ясала яисә юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга - хезмәт өчен түләүнең уннан алып егерме минималь күләменә кадәр, урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең өчтән алып ун минималь күләменә кадәр, гражданнарга хезмәт өчен түләүнең өчтән алып ун минималь күләменә кадәр штраф салына.

13 статья. Җирләрне чүпләү

Җирләрне чүпләгән өчен -

кисәтү ясала яисә юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга - хезмәт өчен түләүнең илледән алып йөз минималь күләменә кадәр, урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең уннан алып егерме минималь күләменә кадәр, гражданнарга хезмәт өчен түләүнең өчтән алып ун минималь күләменә кадәр штраф салына.

14 статья. Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрне чүп үләннәре белән чүпләндерү

Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрне чүп үләннәре белән чүпләндергән өчен -

кисәтү ясала яисә юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга - хезмәт өчен түләүнең илледән алып йөз минималь күләменә кадәр, урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең уннан алып егерме минималь күләменә кадәр штраф салына.

15 статья. Җирләрнең торышы һәм алардан файдалану турында җир законнарында билгеләнгән белешмәләрне дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына тапшырмау, шулай ук әлеге белешмәләрне бозу

Җирләрнең торышы һәм алардан файдалану турында җир законнарында билгеләнгән белешмәләрне дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына тапшырмаган, шулай ук әлеге белешмәләрне бозган өчен -

урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең икедән алып биш минималь күләменә кадәр, гражданнарга хезмәт өчен түләүнең икедән алып биш минималь күләменә кадәр штраф салына.

16 статья. Җир кишәрлекләрен җир турындагы законнар нигезендә инвентаризацияләүгә каршылык күрсәтү

Җир кишәрлекләрен җир турындагы законнар нигезендә инвентаризацияләүгә каршылык күрсәткән өчен -

юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга - хезмәт өчен түләүнең уннан алып утыз минималь күләменә кадәр, урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең биштән алып ун минималь күләменә кадәр, гражданнарга хезмәт өчен түләүнең икедән алып биш минималь күләменә кадәр штраф салына.

17 статья. Җирләрдән файдалануга бәйле проектлау-эзләнү эшләрен билгеләнгән тәртиптә әлеге эшләргә лицензияләр алмыйча яисә лицензиядә каралган шартларны бозып башкару

Җирләрдән файдалануга бәйле проектлау-эзләнү эшләрен билгеләнгән тәртиптә әлеге эшләргә лицензияләр алмыйча яисә лицензиядә каралган шартларны бозып башкарган өчен -

юридик һәм индивидуаль эшкуарларга - хезмәт өчен түләүнең утыздан алып илле минималь күләменә кадәр, урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең биштән алып ун минималь күләменә кадәр, гражданнарга - хезмәт өчен түләүнең өчтән алып биш минималь күләменә кадәр штраф салына.

18 статья. Ызан тамгаларын юкка чыгару

Ызан тамгаларын юкка чыгарган өчен -

юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга хезмәт өчен түләүнең уннан алып утыз минималь күләменә кадәр, урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең өчтән алып жиде минималь күләменә кадәр штраф салына.

19 статья. Жир кишәрлекләрен бирүнен һәм кире алунын жир турындагы законнарда билгеләнгән тәртибен бозу

Җир кишәрлекләрен бирүнең һәм кире алуның җир турындагы законнарда билгеләнгән тәртибен бозган өчен, шулай ук урындагы затларның җирләрне законсыз биләп алуга, жир кишәрлекләре милекчеләренең, аларны биләүчеләрнең һәм жирдән файдаланучыларның хокукларын бозуга китергән хокукка каршы гамәлләре өчен -

урындагы затларга хезмәт өчен түләүнең биштән алып илле минималь күләменә кадәр штраф салына.

20 статья. Административ хокук бозулар турында беркетмәләр

Әлеге Законда күрсәтелгән административ хокук бозулар турындагы беркетмәләр Татарстан Республикасының Җир ресурслары һәм жир реформасы дәүләт комитетының һәм аның урыннардагы органнарының урындагы вәкаләтле затлары тарафыннан төзелә.

21 статья. Әлеге Законда күрсәтелгән административ хокук бозулар турындагы эшләрне карарга вәкаләтле органнар (урындагы затлар)

Әлеге Законда күрсәтелгән административ хокук бозулар турындагы эшләрне Татарстан Республикасының жирләрдән файдалану

һәм аларны саклау буенча дәүләт баш инспекторы һәм аның урынбасарлары, Татарстан Республикасының Җир ресурслары һәм җир реформасы дәүләт комитетының һәм аның урыннардагы органнарының җирләрдән файдалану һәм аларны саклау буенча дәүләт инспекторлары карый.

22 статья. Административ хокук бозулар турындагы эшләрне карау тәртибе

Әлеге Законда күрсәтелгән административ хокук бозулар турындагы эшләр административ хокук бозулар турындагы законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм вакытларда каралалар.

23 статья. Штрафларның суммаларын бүлү һәм куллану

Хокук бозулар өчен әлеге Законда күрсәтелгән штрафлар суммасының 25 проценты - Татарстан Республикасының республика бюджетына, 75 проценты - административ материалларны карау урыны буенча шәһәрләр һәм районнар бюджетларына җибәрелә.

Әлеге Закон нигезендә алынган штрафлар суммалары бары тик җирләрне саклау, туфракның уңдырышлылыгын арттыру, деградациянең төрле төрләренә дучар булган җирләрне торгызуга бәйле максатларда, шулай ук бу гамәлләрне тормышка ашыру һәм җирләрдән файдалануны һәм аларны саклауны дәүләт тарафыннан тикшереп тору буенча проект-эзләнү, фәнни-тикшеренү һәм бүтән эшләрне башкару өчен генә кулланыла.»

2 статья. Әлеге Законны гамәлгә кертү турында

Әлеге Законны рәсми басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты үзенең норматив хокукый актларын әлеге Законга яраклаштырырга тиеш.

Татарстан Республикасы
Президенты
М.Шәймиев

Казан шәһәре,
2000 елның 19 мае
№ 160